УДК 821.512

***Ф.Г. Фәйзуллина,***
***Э.М. Галимҗанова***

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ОБРАЗЫ ҖИРАСТЫ ДӨНЬЯСЫНДА: ӘДӘБИ ФАНТАЗИЯ ҺӘМ МИЛЛИ ХӘТЕР

Данная статья является научным исследованием в области татарского литературоведения и источниковедения, посвященное ранней мемориализации классика национальной литературы Габдуллы Тукая. Она посвящена анализу художественного диалога с Г. Тукаем в загробном мире, представленного в двух взаимосвязанных текстах, которые были опубликованы в журнале «Ялт-Йолт» в 1914–1915 гг. Эти произведения рассматриваются как уникальный источник для изучения восприятия личности и творческого наследия великого татарского поэта его современниками сразу после его смерти.

Авторы исследуют механизмы формирования культурного мифа о поэте, акцентируя внимание на том, как современники Тукая через жанр литературной мистификации («загробный диалог») пытались осмыслить его вклад в национальную культуру. Это позволяет проследить первые этапы «Тукаеведения» как науки и показывает, как уже в первые годы после кончины поэта формировалось его культурное пространство.

Авторы не ограничиваются анализом содержания публикаций, но и контекстуализируют их, вводя в научный оборот материалы периодической печати 1914 года – статьи Г. Ибрагимова, Г. Исхаки, С. Памиева, Ф. Туктарова, М. Гафури. Сопоставительный анализ позволяет реконструировать полемический контекст эпохи и показать, как «загробные» тексты отвечают на конкретные оценки творчества Тукая, дававшиеся в мемориальных публикациях газет «Йолдыз» и «Ил».

**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, татарская литература, литературная мистификация, образ поэта, литературное наследие, мемориализация, диалог с классиком

This article is a scientific research in the field of Tatar literary studies and source studies, dedicated to the early memorialization of the classic of national literature, Gabdulla Tukay. It focuses on the analysis of the artistic dialogue with G. Tukay in the afterlife, presented in two interconnected texts that were published in the journal “Yalt-Yolt” in 1914–1915. These works are considered as a unique source for studying the perception of the personality and creative legacy of the great Tatar poet by his contemporaries immediately after his death.

The authors explore the mechanisms of the formation of the cultural myth about the poet, focusing on how Tukay’s contemporaries attempted to comprehend his contribution to national culture through the genre of literary mystification (“afterlife dialogue”). This allows us to trace the early stages of “Tukay studies” as a science and demonstrates how his cultural space was formed in the first years after his death.

The authors not only analyze the content of the publications, but also contextualize them by introducing into scientific circulation materials from the periodical press of 1914, such as articles by G. Ibragimov, G. Iskhaki, S. Ramiev, F. Tuktarov, and M. Gafuri. A comparative analysis allows us to reconstruct the polemical context

of the era and show how the “afterlife” texts respond to the specific assessments of Tukay’s work provided in the memorial publications of the newspapers “Yoldyz” and “Il”.

**Keywords:** Gabdulla Tukay, Tatar literature, literary mystification, image of the poet, literary heritage, memorialization, dialogue with a classic

Габдулла Тукайның үлеме (1886–1913) XX гасыр башы татар мәдәнияте өчен зур югалту була. Шагыйрьнең вафатыннан соң ук, вакытлы матбугат битләрендә аның шәхесен һәм иҗатын төрле яклап яктырткан мәкаләләр, хатирәләр күренә башлый. Гомеренең соңгы елларында (1910–1913) Тукай зур эшчәнлек алып барган «Ялт-Йолт» (1910–1918) сатирик журналы беренче елларда аеруча зур кайгы кичерә. Берничә ел дәвамында шагыйрь истәлегенә багышланган махсус саннарның (55 нче (1913), 71 нче (1914), 88 нче (1915), 109 нчы (1916)) дөнья күрүе журналның, бу югалту белән килешә алмыйча, аның рухы белән яшәве турында сөйли.

Тукайның үлеменнән соң бер ел үткәч, «Ялт-Йолт» журналының 1914 елгы 71 нче (18 апрель) санында «Җирасты дөньясында Габдулла Тукай» [5] исемле мәкалә басыла. Мәкаләнең авторы үзен «Мин үзем «Кәнҗә бикә исемле бер башкорт кызымын» дип таныштыра. Язма «Тагы бар әле» дигән сүзләр белән тәмамлана һәм тагын бер елдан, журналның 1915 елгы 88 нче (5 апрель) санында, язманың исеме бераз үзгәртелеп, «Г. Тукай җирасты дөньясында» [6] дип аталган дәвамы басылып чыга. Биредә Кәнҗә бикә, җирасты дөньясында Тукай белән күрешкән болгар кызларыннан Көмеш бикәне дә автор буларак күрсәтеп, мәкаләне «К. һәм К.» имзасы белән урнаштыра. «Ялт-Йолт» журналы битләрендә бу имзалар белән язылган мәкаләләр тагын күзәтелә. Әмма аларның кемнеке булуы билгесез.

Әлеге текстлар үзенчәлекле диалог формасында язылганнар. Алар шагыйрь образын мифологик яссылыкта яңадан тудыра, аны сөйләштерә, үз иҗатын һәм милли әдәбиятны читтән торып бәяләтә. Шул ук вакытта бу чорда Тукайга мөнәсәбәтне, аның шәхесенең һәм иҗатының татар җәмгыятендә кабул ителешен чагылдырган кызыклы чыганак булып тора.

Язмалар мавыктыргыч композициягә корылган: кабердәге «Тукай» белән очрашу, «шагыйрь» белән әңгәмә, төрле актуаль мәсьәләләр буенча фикер алышу. Шагыйрьнең «җирасты дөньясы» белән фани дөнья арасында бәйләнеш урнаштыру мотивы – әдәби-фәлсәфи яктан кызыклы алым.

Язмалардагы беренче зат исеменнән сөйләүче Кәнҗә бикә җеннәр ярдәме белән җирасты дөньясына үтеп керә алган. Ул анда Көмеш бикә исемле дусты белән очраша һәм аның белән бергә Тукай каберенә бара. Алар «Тукай» белән сөйләшүгә ирешәләр. «Шагыйрь» үз иҗаты, башка әдипләр, милләтнең киләчәге турындагы фикерләрен җиткерә.

Язмаларда «Тукай» үзенең татар әдәбиятындагы урынын һәм әһәмиятен тирәнтен аңлаучы шәхес буларак сурәтләнә. Ул үзен татар

милләтенең «мәңгелек санәме» *(символы)* итеп күрсәтә: «Мин садә *(гади)* идем, мин садә тордым, мин садә яздым. Мин шул хәлем белән татарның әхвәл вә торышына бер санәм булдым. Мин мәңгелек санәм булдым. Минем язган нәрсәләремдә татарның телен, татарның халәте рухиясен, татарның әхлакын энәсеннән җебенәчә күрерсез» [5].

«Тукай»: «Мин шагыйрь булырга теләмәдем. Мин шагыйрь булырга омтылмадым, мин дөньяда торырга теләдем. Мин, дөньяда торып, эш эшләргә теләдем... Ләкин милләт вә әхвәл мине канәгать иттерерлек эшне миңа бирә алмады, мин үземә ярарлык эшне милләт эчендә таба алмадым. Шуннан соң әхвәлгә тарсынып, мин ачу белән үземнең хисләремне фаш итә башладым. Мин ирекледән түгел, ирексездән сөйләнә башладым. Мин бит язар өчен бер мәүзуг *(тема)* тотмадым. Мин бит телгә, я фикергә, я башкага хезмәт итәм дип керешмәдем; мин һәрвакыт эчемне пошырган, мине борчыган, мине хәрәкәткә китергән эшләргә карап сүз сөйләдем...» – дип, үзен иң элек милләт эшлеклесе итеп тануларын тели [5].

1914 елда басылган «Җирасты дөньясында Габдулла Тукай» язмасында «шагыйрь»нең Г. Ибраһимов, С. Рәмиев, Г. Исхакый, Ф. Туктаровларга карата кайбер тәнкыйди фикерләре яңгыраш таба. Алар замандашларының иҗатына бирелгән бәяләмәләр аша җиткерелә.

«Йолдыз» газетасының 1914 елгы 2 апрель (1158 нче) санында Г. Ибраһимов, Тукайга багышлап, «Талант трагедиясе» исемле мәкаләсен бастыра. Әдипнең бу мәкаләдәге «син хатыннардан качмаган булсаң, табигатьтән кызык тапкан булсаң, китап укып мәгълүмат арттырган булсаң, шәп шагыйрь булачак булгансың» [2] дигән фикерен «Тукай» кискен кире кага. «Галимҗан бик салкын фәлсәфәгә керешкән, минем шигыремне шәп иттереп кайда куймакчы була да ул шәп шигырьне ни дип белә? Имеш, мин Пушкиннар, Лермонтовлар кебек булырга тиеш булганмын!» [5] – ди.

Автор «мин Габдулла янына «Ил»дән нөсхә алып барган идем» дип, игътибарны «Ил» газетасының 1914 елның 2 апрелендә (№ 23) Тукайга багышлап чыгарылган махсус санына юнәлтә. Г. Исхакыйның биредә басылган «Милли фаҗига» исемле баш мәкаләсе, Ф. Туктаровның «Онытылмаслык үкенеч», С. Рәмиевнең «Икенче апрель көне», М. Гафуриның «Габдулла Тукай Уфада» мәкаләләре – барысы да Г. Ибраһимов фикерләрен дәвам иттерәләр.

Г. Исхакый үзенең «Милли фаҗига» мәкаләсендә, «шагыйрьнең шигърият куәсенең үткерләнүе, чарлануы өчен, шагыйрьнең үткенлеге, шагыйрьнең яшүсмерлеге, мәхәббәт-гыйшык арасында үтәргә кирәк, шагыйрьнең шигыре нечкә кылдан үткен булсын өчен, аның күңеле Мәҗнүндәге мәхәббәт куәсеннән артык көч берлә гыйшык утында янарга кирәк…» дип, Тукайны ачылып бетмәгән шагыйрь буларак тасвирлый. Үлеменең сәбәпләре буларак: «Габдулланың йөрәк җылысы юклыгы, бер татар кызының аны сөймәве, бер татар кызының аны «шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев җәнаплары» димәенчә, Габдулла дип кенә каравы үтерде» [3], – дип күрсәтә.

Җавап буларак, «Тукай» аңа: «Имештер, мин «егетлегем өчен» кызлар тарафыннан сөелмәгәнмен дә шуның өчен шәп шагыйрь булмаганмын! Гаҗәп, рәзе *(разве)* мин алай сөелерлек бер егет идем. Бәлки «Ил» мөхәрриренең үзен дә «матур егет» дип сөюче татар кызы юктыр әле...» [5], дип җавап бирә. Әлеге фикер С. Рәмиевнең «Икенче апрель көне» язмасында да үстерелә: «Ул мине ярма дигән! Ул мине «бер бөртек тары ярмасы» дигән! Имеш, ул мине күрмәмеш булып торган! [5] – дип, С. Рәмиевнең: «Тукаев мәрхүм дә татар хәятының шундый бер корбаны булды. Ул татар галәме өчен бүрткән бер ярма, зур бер гатыя *(бүләк)* иде... Аның вөҗүд булуы, үсүе, бер кеше татар җәмәгасының каравына карап, тәрбиясенә тапшырылган иде. Татар җәмәгасы үзе дә аның әзер бер ярма, зур бер гатыя икәнен ачык белгән иде. Ләкин һәрвакыттагы мәнсез (мәгънәсез)легенчә: «Бер тарыдан ботка булмас», – дип, халкымыз шуны күрәләтә тегермән ташы астына издертеп харап итте» [7], дигән сүзләренә мөнәсәбәтен белдерә.

Бу фикер Ф. Туктаровның «Онытылмаслык үкенеч» мәкаләсендә дә, «Тукай бик яшьли үлеп китте, күп нәрсәсен язып өлгерә алмый калды» [8], дип дәвам иттерелә. «Тукай»: «М.Ф. бит инде укып кына түгел, хәтта табигатьнең үзе тарафыннан ук шулай хокукшинасрак *(юрист сыманрак)* ясалган» «Шәкертлеге беткәч, болай язмый башлар әле» [5], дип, аңа да тыныч кына үз сүзен әйтә.

Тукай шушы кыска гомере эчендә язган әсәрләре белән дә үзен халкының бөек шагыйре итеп танытырга өлгерде. Бу мәкаләләр язылганда Тукайның үлеменә бары бер ел гына үткән була. Шул сәбәпле, үкенечкә нигезләнгән әлеге мәкаләләрдә Тукайга бәя шагыйрьне югалтуга бәйле йөрәк сыкравы аша җиткерелә. Аларда яктыртылган «Шагыйрьнең вакытсыз үлеме булмаса, аның таланты киләчәктә тагы да киңрәк ачылган булыр иде», дигән фикерне Тукайны бәяләүнең беренче этабы буларак карарга кирәктер.

Кәнҗә бикә, шул рәвешле, Тукайның үлемен үкенечкә генә бәйләп, аның ачылып бетмәгән талант буларак бәяләнүен кабул итми. Киләчәктә шагыйрьне бәяләү тиешле дәрәҗәдә булачагын ассызыклап, автор «Тукай»дан түбәндәге фикерләрне җиткертә: «Мин бит никадәр бер яклы булсам да, мин никадәр яшь булсам да, үземә бер школа ясап калдыра алдым. Минем школамның шәкертләре тиз җитешерләр, алар эшләрен алга җибәрерләр», [5] дип, иҗаты киләчәктә җентекле өйрәнеләчәгенә, яңача бәяләнәчәгенә өметләр баглый.

Шагыйрьнең милләткә карата мөнәсәбәте һәм үз иҗатының милли әһәмияте турындагы фикерләре «Тукай»ның «Әгәр татар тәрәккый итсә, әгәр татар юнәлсә, әгәр татар, бер милләт хәленә килдем, дисә, мотлакан, үзенең теле, үзенең халәте рухиясе вә үзенең әхлакы белән барыр» [5], дигән сүзләрендә яңгыраш ала. «Мин татар, чын татар идем. Шуның өчен минем тиз җитлегүем татарлыгымнан, татарлыкта табигыйлыктан килгәндер. Мәгәр минем бар хәзинәм чыккан иде», [5] дип, ул үз гомеренең кыскалыгын һәм шул ук вакытта тулылыгын

күрсәтә. Шул рәвешле Тукай иҗатының киләчәктә үз югарылыгын алачагы ассызыклана.

Кәнҗә бикәнең Көмеш бикә белән берлектә язган «Г. Тукай җирасты дөньясында» (1915) мәкаләсендә әңгәмәгә оста гына Тукай үлеменнән соңгы яңалыклар кертеп җибәрелә. Авторлар «Тукай»га «Бу арада Мәрҗани Шиһаб хәзрәтенең тәрҗемәи хәле хакында алтыҗиде йөз битле бер китап чыкты» [6], дип, мәгърифәтче, дин галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818–1889) тууына 100 ел тулу уңаеннан 1915 елда Казанда дөнья күргән 639 битле «Мәрҗани» исемле җыентык турында хәбәр итәләр. «Тукай» чак кына башын тотып тора да:

*Чыкты, ахры, бездән дә бер бөтен кеше,*
*Яхшы аңлап, тәкъдир итү читен кеше;*
*Татарда гыйрфан (аң, белем) уты кабынганны*
*Күрсәтергә күтәрелгән төтен кеше* [6], –

дип, үзенең «Шиһаб хәзрәт» (1913) шигыреннән бер өзек укып күрсәтә. «Г. *(Габдулла)* әфәнде, сез Шиһаб хәзрәтне җирасты дөньясында күргәнеңез бармы?» дигән сорауга, «ул» текә генә: «Юк, һич күргәнем юк, ул бит башка юл кешесе иде» [6], – дип җавап бирү белән канәгатьләнә.

Ә «Габдулла әфәнде, Каюм абзый белән күрешәсезме?» – дигәч, «Тукай», бераз мыек астыннан елмаеп: «Күрешәбез, нигә?» [6] – ди. Шулвакыт татар дөньясындагы яңалыклардан хәбәрдар булган авторлар әдәбият дөньясыннан шагыйрь Г. Тукай белән мәгърифәтче К. Насыйрины чагыштырырлык уртак сыйфатлар эзли башлыйлар. Г. Исхакыйның «Мөгаллимә» (1914) драмасындагы Фатыйма исемле мөгаллимәнең бу шәхесләр турында «...Сукыр Каюмны хәтерләңез!.. Кырык ел гомерен татар тормышында ялгыз үткәргәнен, үлгәндә янында йомшак сүзле бер кешесе булмаганын исеңезгә төшереңез. Кичә генә әле үлгән Габдулла Тукаевны, гомерендә бер мәртәбә татар кызыннан сөйкемле сүз, сөйкемле бер хәрәкәт күрмәгән шул татар шагыйренең дә хәлен, трагедиясен уйлаңыз! Мин боларның икесендә дә татар хатыны бурычлы калды, вазифасын үти алмады, дия алам һәм дим» [4: 297] дигән сүзләрен искә төшереп, «шагыйрь»дән «мөгаллимәнең сезнең икеңезне сөйми ашыктырып үтерүдә татар кызларын гаепләвен ничек таптыңыз?» [6] дип кызыксыналар. Бу сорауга «Тукай»: «Каюм абзый бу сүздән бик көлде. Аны язган кеше татар кызларыннан берәр әдипне сөйдерер өчен эшләгәндер инде...» [6], – дип кенә әйтә ала.

Язмаларда Тукайның шәхси сыйфатлары хакында да кызыклы фикерләр табарга мөмкин. Хатын-кызларга мөнәсәбәте турында мәкалә авторы: «Т. *(Тукай)* бит дөньяда хатын-кызлардан качса да, үзе күңеленнән хатын-кызларны сөя икән, аның качуы да аларның бизүеннән куркып кына булган» [6], – дип яза һәм Тукайның Җаектан Казанга килгән чакларындагы бер кызык хәлне сөйләп: «Мәгәр ул, күренештә вә утырышта чибәр кызлар тарафыннан чын мәгънәсе

белән сөелерлек хәлдә булмаганына үкенеп, ошбуында мәзкүр шигырьләрен сөйләгән вә үзен ишетеп яраткан кызларны, үзен күрсәтеп биздермәс өчен, кача торган булган» [6], дигән нәтиҗәгә килә.

Тукай белән әңгәмә барышында татар әдәби мохитендәге төрле бәхәсләр, полемикалар искә алына. Г. Ибраһимовның «Аң» журналы өчен әзерләнгән «Альбом (сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)» турындагы бәхәс аеруча кызыклы. Рәсем сәнгате үрнәкләрен эченә алган әлеге альбом басылып чыгу белән, татар матбугатында хезмәтнең җитешмәгән якларын күрсәткән аерым мәкаләләр күренә башлый. Мәсәлән, «Кояш» газетасының 1915 елгы 20 март санында имзасыз басылган «Аң» альбомы» исемле бәяләмә шундыйлардан. «Кармак» журналы да (1915, 7 нче сан) Г. Ибраһимов төзеп бастырган «Альбом»ны тәнкыйть утына ала. Заманында җәмәгатьчелектә җиңелчә резонанс тудырган әлеге мәсьәләне кузгатып, Кәнҗә бикә «Тукай»га да бу хәбәрне җиткерүне кирәк таба. «Әле сезнең (чөнки мин үзем Өфенеке) Казанда бер ятрак нәрсә бар. Г. И. *(Галимҗан Ибраһимов)* «Матур эшләр»гә тарызында бернәрсә тәртип итеп, «Гасыр»га биргән. Шул матур эшләр өстендә байтак кына имеш-димешләр бар. Ул «Матур эшләр» китабын рәтсезлектә гаеплиләр, мөселманнарга христиан рәсемнәрен бирүдә гаеплиләр, китабының ахырына әллә никадәр тәрҗих *(аермалыклар)* белән мәрҗихләр ясап, берничә шәхеснең рәсемен кертүдә гаеплиләр» [6], – ди. Рәсем ияләренең берничәсен санаганнан соң, автор, «Альбом» турындагы гомуми фикерләрне җыеп, «Тукай»дан «Бу дөньяда минем көчем юк шул инде. Мин Галине сөйгәнемнән булмаса да, Мөгавиягә ачуым белән дә, ул “Матур эшләр” хакында берәр әйтеп ташлаган булыр идем, юк шул инде, мин әйтә алмыйм шул. Минем школамның шәкертләре күптән миңа иярсәләр дә, кешене тәмам татар безе белән чәнчүдә, татар бармагы белән кешенең күзенә төртә белүдә минем кебек эшли алмыйлар» [6], дигән сүзләрне әйттерә. Автор Тукайдан соң җир өстендә «андый кешене кырмыска кебек тешләрлек, чаян кебек чагарлык, карчыга кебек тибәрлек» [6] әдипләр калмаганлыкка борчылып куя.

Язмаларда Тукай шигъриятенең тирәнлеге, фикерләренең үткенлеге дә ачык чагыла. «Үземнең “Өзелгән өмид”емдә, ул халыктан да өмид өзеп:

*Күпме моңлансам кунып милли агачлар өстенә,*
*Барсы корган – бер генә юк җанлысы, яфраклысы, –*

дигән идем. Әле ул агачлар бераз тереклек суылдавы күрсәтәләр бит» [6], – ди Тукай. Бу сүзләрдә шагыйрьнең милләтнең киләчәгенә өмете чагыла.

Үлемнән соң да «шагыйрь» актуаль мәсьәләләргә мөнәсәбәтен белдерә, үз шигырьләреннән, «Өзелгән өмид» (1910) шигыренә аеруча еш мөрәҗәгать итә. Кәнҗә бикә «Тукай»дан әлеге шигырьдәге:

*Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә,*
*Яшь һилал урынында анда тулган айның яктысы, –*

дигән сүзләрнең мәгънәсен аңлатып бирүен үтенә. «Тукай»: «Минем иң шәп шигырь язган елларым җиденче, сигезенче еллар булып, ул еллар минем гомеремнең яңа туган ае гына булырга тиеш иде, хәлбуки ул вакытлар минем гомеремнең тулган ае булганы хәзер дә миңа мәгълүм булыр. Ул вакытта минем аем тулган булган икән һәм аннан бирле кими башлаган, хәзер дә исә минем гомерем бетә торган иске ай мәртәбәсенә килгән, дигән сүзне ирадә кылдым *(әйтергә теләдем)*» [6], – ди. «Сизлә: үтте яшь вакытлар, җитте гомрем ягтысы», диюдә шагыйрьлек гомере турында сүз барганлыгы аңлашыла.

Кәнҗә бикә, авыр булса да, Габдулла Тукайның яшьли үлеме белән килешә. Җир өстендә тәмам татарча Тукайның елын уздырулар, каберенә килеп, Коръән багышлаулар да аның күңеленә хуш килгән булса кирәк. Ул шунда үзалдына «Габдулла Т. ны тагы кайчан телгә алырлар икән?» дигән сорау бирә. Һәм үзе үк бер дә шикләнмичә: «Мәетнең ике елы булмый. Бәлки татарда мәет елыннан соң, әбәдән *(мәңгегә)* онытылырга мөмкин, чөнки актык мәртәбә яд ителүе *(искә алынуы)*, анда да ялгыз Коръән укылу белән генә телгә алына. Әгәр инде Габдулла Т. хакында "ике ел", "өч ел" дигән кебек берәр нәрсә чыгарсалар, ни әйтик...» [6] – дип, Габдулла Тукайның татар дөньясында мәңгелек йолдыз булып кабыначагын алдан ук күзаллый.

«Җирасты дөньясында Габдулла Тукай» (1914) һәм «Г. Тукай җирасты дөньясында» (1915) язмалары Тукайның үлеменнән соң татар


№ 88 یکشنبه ۵ نچی آپریل ۱۹۱۵ سنه

ЯЛТЪ-ЮЛТЪ

یالط-یولط

«Ялт-йолт» журналының 1915 елгы 88 нче (5 апрель) санының титул бите


ع. توقای یر آستی دنیاسنده.

Шул ук санның «Г. Тукай җирасты дөньясында» мәкаләсе басылган 9 нчы бите

әдәбиятында аның образын һәм иҗатын аңлауның үзенчәлекле формасы булып торалар. Алар аша без 1910 еллар татар әдәби мохитен, әдәби бәхәсләрне, мәдәни казанышларны һәм проблемаларны да күрәбез.

Әлеге язмаларда, шагыйрьнең иҗатын идеаллаштырудан тыш, тирәнрәк мәгънәви анализга омтылыш ясалган. Тукай гади образ буларак түгел, ә катлаулы, каршылыклы шәхес буларак күрсәтелә. Ул үз иҗатының әһәмиятен һәм чикләрен аңлаган, үзенә бәя бирә алган, милләтнең киләчәген кайгыртучы шәхес буларак сурәтләнгән. Үлеменнән соң бер ел үтүгә үк, шагыйрь татар милли аңында үзәк фигура, милли символ буларак урнашкан. Аның шигырьләре милли хәзинә буларак кабул ителгән, сүзләре, фикерләре замандашлары тарафыннан югары бәяләнгән. Бу язмалар – Тукай шәхесен һәм иҗатын милли хәтердә саклауның тәүге адымнарыннан берсе буларак, бүгенге көн Тукай фәнен барлыкка китерүгә этәргеч биргәннәр дисәк, ялгышмабыз.

**Әдәбият**


1. *Гафури Мәҗит.* Габдулла Тукай Уфада // Ил. 1914. 2 апрель.
2. *Ибраһимов Галимҗан.* Талант трагедиясе // Йолдыз. 1914. 2 апрель.
3. *Исхакый Гаяз.* Милли фаҗига // Ил. 1914. 2 апрель.
4. *Исхакый Гаяз.* Мөгаллимә // Әсәрләр. 15 томда. 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 496 б.
5. *Кәнҗә бикә.* Җирасты дөньясында Габдулла Тукай // Ялт-Йолт. 1914. 18 апрель.
6. *К. һәм К.* Г. Тукай җирасты дөньясында // Ялт-Йолт. 1915. 5 апрель.
7. *Рәмиев Сәгыйть.* Икенче апрель көне // Ил. 1914. 2 апрель.
8. *Туктаров Фуад.* Онытылмаслык үкенеч // Ил. 1914. 2 апрель.



***Фәйзуллина Фәния Галимулла кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәре*

***Галимҗанова Эльмера Мәхмүт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Файзуллина Фания Галимулловна,***
*научный сотрудник отдела текстологии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*fania.f@mail.ru*

***Галимзянова Эльмера Махмутовна,***
*кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник отдела текстологии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*elmera.galimzyanova@mail.ru*